**СОВЕТ ГОРОДА МАМАДЫШ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**ул. М. Джалиля, 23/33, г. Мамадыш, 422190**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАМАДЫШ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**
**М.Җәлил ур., 23/33, Мамадыш ш., 422190**

**тел.:(85563) 3-15-90, факс 3-24-00 ; e-mail:gorsovet.mamadysh@tatar.ru**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 1-28** **«19» ноябрь 2018 ел**

2018 елның 18 ноябрендә референдумда
кабул ителгән карарны теркәү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында» 2004 ел, 24 апрель, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, 2018 елның 18 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча уздырылган референдум нәтиҗәләре нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында катнашканнарның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәреннән кала, шулай ук үзара салым акчасының 50% ташламасы белән көндезге бүлектә белем алучы студентлар файдалана, 2019 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1). 1.Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында җирлек чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

- Мамадыш шәһәре территориясендә электр линияләрен төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау.

2. Җирлектә яшәүче халыкның бергә җыелып ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның җыелып ял итү урыннарын төзекләндерү, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле керә алуын тәэмин итү;

- Мамадыш шәһәре территориясендә пляжны төзекләндерүне оештыру.

« ӘЙЕ » « ЮК »

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында» 930 номерлы карарын теркәргә.

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Шәһәр башлыгы,
Мамадыш муниципаль районының
Мамадыш шәһәре Советы рәисе А.П. Иванов